**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
ЧЕРЕМШАНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

06.02.2026 **Чирмешән авылы** **№ 39**

**Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының «2026 елга Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы халкына күрсәтелә торган торак хезмәтләре өчен түләү күләмен раслау турында» 2025 елның 18 декабрендәге 406 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Торак кодексының 156,158 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне карап тоту кагыйдәләрен һәм күпфатирлы йортта тиешле сыйфатта булмаган гомуми мөлкәт белән идарә итү, карап тоту һәм ремонтлау буенча хезмәтләр күрсәткән һәм эшләр башкарган очракта һәм (яисә) билгеләнгән дәвамлылыктан артыграк тәнәфесләр белән торак урынны карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләмен үзгәртү кагыйдәләрен раслау турында» 2006 елның 13 августындагы 491 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының «2026 елга Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы халкына күрсәтелә торган торак хезмәтләре өчен түләү күләмен раслау турында» 2025 елның 18 декабрендәге 406 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 нче кушымтага 10 нчы юлны өстәргә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 10 | Гомуми файдаланудагы йорт эчендәге урыннарны җыештыру | айга торак урынның гомуми мәйданының кв.м. | 2,25 |

2. Карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2026 елның 01 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына М.Г. Вильдановка йөкләргә.

Башкарма комитет
җитәкчесе И.М. Җамалетдинов

Чирмешән муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесенең
«06»02.2026 ел, № 39 карарына
1 нче кушымта

Күпфатирлы торак йортлар белән идарә итү ысулын сайламаган торак урыннар милекчеләре өчен, муниципаль торак фондының торак урыннарын яллаучылар өчен торак урынны карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләме, күпфатирлы торак йортлар белән идарә итү ысулын сайлаган торак урыннар милекчеләре өчен һәм күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар һәм (яисә) гомуми җыелышта торак урыннарны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре өчен түләү күләме

| № п/п | Түләү атамасы | Хезмәтне үлчәү берәмлеге | Хезмәт күрсәтүне үлчәү берәмлеге өчен тариф (сумнарда) |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1 | Торак фонды белән идарә итү | аена торак бинаның гомуми мәйданы кв.м. | 2,28 |
| 2 | Торак биналарны агымдагы ремонтлау | аена торак бинаның гомуми мәйданы кв.м. | 1,55 |
| 3 | Йорт эчендәге сууткәргеч-канализация челтәрләренә техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау | аена торак бинаның гомуми мәйданы кв.м. | 1,84 |
| 4 | Йорт эчендәге электр белән тәэмин итү челтәрләрен агымдагы ремонтлау һәм карап тоту | аена торак бинаның гомуми мәйданы кв.м. | 1,72 |
| 5 | Вентиляция каналларына техник хезмәт күрсәтү | аена торак бинаның гомуми мәйданы кв.м. | 0,40 |
| 6 | Дератизация (дезинсекция) | аена торак бинаның гомуми мәйданы кв.м. | 0,20 |
| 7 | Газүткәргечнең йорт эчендәге челтәрләренә техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау | аена торак бинаның гомуми мәйданы кв.м. | 0,28 |
| 8 | Йорт яны территориясен җыештыру | аена торак бинаның гомуми мәйданы кв.м. | 1,55 |
| 9 | Газ челтәрләренә техник диагностика ясау (түләү диагностика ясау срогы | аена торак бинаның гомуми мәйданы кв.м. | 0,25* |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | башланганчы 12 ай эчендә исәпләнә) | | |
| 10 | Гомуми файдаланудагы йорт эчендәге урыннарны җыештыру | айга торак урынның гомуми мәйданының кв.м. | 2,25 |

* газүткәргеч файдалануга тапшырылуга 30 ел узган күпфатирлы йортлар өчен.